**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЮТАЗЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# К А Р А Р

**№ 10** **Ютазы ав.** **«22» июль 2024 ел**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Советының 2023 елның 31 маендагы 12 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Ютазы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Советының 2023 елның 31 маендагы 12 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 23 маддәсендәге 7 өлешендәге 5 нче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«бюджет ассигнованиеләре бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыруга яңадан кертелгән һәм Россия Федерациясе дәүләт милке объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыруга субсидияләр биргән очракта».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Ютазы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Татарстан Республикасының http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталы составында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгән көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Ютазы авыл җирлеге башлыгы Л.М.Хәйруллина